**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 25 февраль № 115

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләре турында» 2012 ел, 23 гыйнвар, 35 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 22 июнь, 542 нче, 2013 ел, 4 июль, 477 нче, 2014 ел, 26 апрель, 270 нче, 2015 ел, 30 аперль, 301 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2016 елда югары белеме булган, 2016 елда Татарстан Республикасының авыл торак пунктына яисә эшчеләр поселогына (шәһәр тибындагы поселокка) эшкә килгән, яки башка торак пунктыннан Татарстан Республикасының авыл торак пунктына яисә эшчеләр поселогына эшкә күчеп килгән һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән килешү төзегән 50 яшькәчә медицина хезмәткәрләренә (алга таба – медицина хезмәткәрләре) бер медицина хезмәткәренә 400,0 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен билгеләргә.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Медицина хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү һәм бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү тәртипләрен раслау турында» 2012 ел, 13 февраль, 111/1 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 4 июль, 477 нче, 2014 ел, 26 апрель, 270 нче, 2015 ел, 30 апрель, 301 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Медицина хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү тәртибендә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип югары белеме булган, 2016 елда Татарстан Республикасының авыл торак пунктына яисә эшчеләр поселогына (шәһәр тибындагы поселокка) эшкә килгән, яки башка торак пунктыннан Татарстан Республикасының авыл торак пунктына яисә эшчеләр поселогына эшкә күчеп килгән һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән килешү төзегән 50 яшькәчә медицина хезмәткәрләренә (алга таба – медицина хезмәткәрләре) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен (алга таба – компенсация түләүләре) гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләрен билгели.»;

5 һәм 6 пунктларда «өч» сүзен «биш» сүзенә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Медицина хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү тәртибендә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип югары белеме булган, 2016 елда Татарстан Республикасының авыл торак пунктына яисә эшчеләр поселогына (шәһәр тибындагы поселокка) эшкә килгән, яки башка торак пунктыннан Татарстан Республикасының авыл торак пунктына яисә эшчеләр поселогына эшкә күчеп килгән һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән килешү төзегән 50 яшькәчә медицина хезмәткәрләренә (алга таба – медицина хезмәткәрләре) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен (алга таба – компенсация түләүләре) гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләрен билгели.»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы 2016 елда медицина хезмәткәрләренә бер тапкыр компенсация түләүләре гамәлгә ашырыла торган айга кадәр булган айның 13енә кадәр төзелгән шартнамәләр нигезендә түбәндәгеләргә заявкалар тапшыра:

«Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләве территориаль фонды» дәүләт учреждениесенә – Россия Федерациясе Мәҗбүри медицина иминиятләве федераль фонды билгеләгән форма буенча 600,0 мең сум күләмдә компенсация түләве алуга;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы фонды билгеләгән форма буенча 400,0 мең сум күләмдә компенсация түләве алуга.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\115.docx